# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ

# КАРАРЫ

**№1** **11.11.2022 ел.**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Чемодурово авыл җирлеге составына керүче
Чемодурово авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131 ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә,1 нче группа, 2 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзалары булган гаиләләрдән кала, бер тапкыр түләүне киметеп, 250 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә ризамы:
- «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел», «Авыл көне» бәйрәм чараларын уздыру буенча хезмәтләр күрсәтү, бүләк продукциясе сатып алу;
- үлән чаптыру, Чемодурово авылы территориясендә чүп-чар җыю буенча хезмәт күрсәтүләр;
-тракторчыга хезмәт хакы;
трактор өчен ягулык-майлау материаллары;
-җиһазлар сатып алу;
-балалар мәйданчыкларын ремонтлау һәм буяу;
-Чемодурово авылы мәдәният йорты өчен сәхнә костюмнарын сатып алу;
- Чемодурово авылы юллары өчен вак таш сатып алу

“РИЗА” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 251 кеше кертелгән, 180 кеше тавыш бирүдә катнашкан.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:
"Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 178 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Азнакай муниципаль районы Чемодурово авылында халык җыены үткән дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә,1 нче группа, 2 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзалары булган гаиләләрдән кала, бер тапкыр түләүне киметеп, 250 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә ризамы:

- «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел», «Авыл көне» бәйрәм чараларын уздыру буенча хезмәтләр күрсәтү, бүләк продукциясе сатып алу;

- үлән чаптыру, Чемодурово авылы территориясендә чүп-чар җыю буенча хезмәт күрсәтүләр;

-тракторчыга хезмәт хакы;

трактор өчен ягулык-майлау материаллары;

-җиһазлар сатып алу;

-балалар мәйданчыкларын ремонтлау һәм буяу;

-Чемодурово авылы мәдәният йорты өчен сәхнә костюмнарын сатып алу;

- Чемодурово авылы юллары өчен вак таш сатып алу

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырыга: http//aznakayevo.tatar.ru һәм Чемодурово авылы, Үзәк урамы , 4А йорт , Молодежная урамы, 20А адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чемодурово авыл җирлеге башлыгы Н.Б.Котельникова